Т.Ш.Гыйлаҗев,
филол.ф.канд., доцент
(Казан)

# Гыйльми-тәнкыйди фикердә М.Гафуриның иҗат ысулы мәсьәләсе

Мәҗит Гафури – татар халкының рухи-мәдәни күтәрелешендә, милли сүз сәнгатенең үсеш-үзгәрешендә зур роль уйнаган язучыларның берсе. Мәгълүм булганча, әдип иҗаты XX гасыр башында Яңарыш (Ренессанс) процессы кичергән татар әдәби хәрәкәте, милли чынбарлык белән тыгыз бәйләнгән. Татар сүз сәнгатенең үсеш-үзгәреш тенденцияләре, закончалыклары әдип әсәрләрендә дә чагылыш таба. Гомер юлының һәр мизгелен иҗатка багышлаган язучының әдәби мирасын гыйльми-нәзари яктыртуның бай тарихы бар. Милли һәм халыкчан әдип иҗатына заманында могътәбәр шәхесләр Р.Фәхретдин, Г.Исхакый, Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Камал, Г.Ибраһимовлар һ.б.лар игътибар итеп чыга. Тәнкыйди язмаларда М.Гафури шигърияте һәм прозасының идея-эчтәлеге, тематикасы, әсәрләренең сәнгатьчә эшләнеше, шигырь төзелеше һ.б. мәсьәләләр күтәрелә. Алар язучының кеше яшәешен матур әдәбиятта сәнгатьчә гәүдәләндерү, авторның иҗаты ысулы проблемасы белән тыгыз бәйләнештә шәрехләнә.

М.Гафуриның XX гасыр башы иҗаты тәнкыйтьчеләрнең татар әдәбиятының үсеш юлы турындагы уйланулары белән тыгыз бәйләнештә тикшерелә. Гыйльми-тәнкыйди эшчәнлекләрендә мәдәни-тарихи мәктәпнең кагыйдәләренә таянган әдипләр М.Гафури рухи мирасына иҗтимагый-милли, рухи-әхлакый яссылыктан якын килеп, әдәби әсәрдә тормыш дөреслеге, иҗтимагый яктан әһәмиятле мәсьәләләр яктыртылуны яклап чыгалар.

Әдип хакында тәүге фикерләр вакытлы матбугат битләрендә 1906 елларда күренә башлый. Мәсәлән, татар халкының мәшһүр заты Р.Фәхретдин “Вакыт” газетасы битләрендә М.Гафури шигъриятенең милли характерын, шагыйрьлек сәләтен уңай бәяли. Бу еллар тәнкыйтендә күбрәк аның проза әсәрләре шәрехләнә. Билгеле булганча, М.Гафури гади халыкның авыр,

михнәтле тормышын реаль вакыйгаларда реалистик буяуларда сурәтләве белән аерылып тора. Аерым алганда, язучының 1908 елда дөнья күргән “Үги балалар” әсәре укучыларда кызыксыну уята. Әйтергә кирәк, хикәядә гәүдәләнгән күренешләр, хәлләр тормыш дөреслегеннән ерак тора. Әдәби әсәрне бәяләгәндә, тормыш дөреслеге тасвирлануны төп критерий итеп кабул иткән Ф. Әмирхан, Г.Камал, Г.Исхакыйлар бу хикәягә тискәре мөнәсәбәт белдерәләр. Алар тарафыннан язылган рецензияләрдә вакыйгаларның укучыларны ышандыру көченә ия булмавы, ясалмалылык, конфликт үстерелешенең реаль җирлеккә корылмавы, тормыштан ераклыгы кискен тәнкыйтьләнә: “Монда “мөхәррир” әфәнде үткән татар ханнарын мактап язган шигыре белән башлап, төрле-төрле белә торган “фикер”ләрен сөйләп бетергәннән соң, бер татар хатынын өч кател (үтерү) җинаятендә гаепле ясап тәмам итәдер. “Үги балалар”ның шушы ахыргы җирләрен укыганда, Әбугалисина кыйссасындагы агач гаскәрләрнең кешеләр үтерүләре, яки яңа гына чыккан «Җанлы җеназа» исемле җансыз әсәрдәге харикыльгадәләр (гадәттән тыш хәлләр) шикелле нәрсәләр искә төшә” [1, 32 б.], - дип яза Ф.Әмирхан.

Г.Исхакый шулай ук китапта рухи-мәдәни яктан яңару, зур үзгәрешләр юлына баскан татар милләте өчен әһәмиятсез, яраксыз вакыйгалар тасвирлануны раслаганнан соң, әсәр каһарманнарының “тышкы тормышларына артык әһәмият бирмәенчә, эчке тормышларын ачыграк күрсәтүне” таләп итеп чыга: “Мөхәррир әфәнде балаларның кыйналуларын, катыкка буялып, былчыранып гомер кичерүләрен бәян итсә дә, аларның күңел сыныкларын, аларның эчке тормышларын тасвир итмәгәнгә, китап, эчке куыш агач кебек, тыштан китап булса, эчтән буш кебек күренә” [5, 143 б.]. Геройларның тышкы тирәлек, рәхимсез чынбарлык тәэсирендә рухи халәтләренең үзгәреше тасвирланмау, әсәрнең психологик анализ элементлар белән баетылмавы Г.Исхакыйда ризасызлык тудыра. Рецензент шулай ук язучының вакыйгалар үстерелешендәге төгәлсезлекләрне, әсәр төзелешендәге кимчелекләрне күрсәтә.

Мәгълүм булганча, Г.Тукайның тәнкыйди мирасында М.Гафури иҗатын бәяләгән язмалар бер шәлкем хасил итә. Төрле стильдә язылган “Милләткә файда урынына зарар” (1910), “Акыллы башлар” (1910), “Өч баш” (1911) һ.б. язмаларында Тукайның шагыйрь поэзиясе хакындагы кайбер бәя-хөкемнәре бәхәсле булса да, “Яңа әсәрләр” (Хәмитнең хәяты)” (1911) рецензиясендә М.Гафуриның повесте мәктәп-мәдрәсәләрдә уку-укыту мәсьәләләре, шәкертләр көнкүреше реаль детальләрдә, дөрес итеп күрсәтелү ягыннан уңай бәяләнә: “М.Гафуриның бу әсәре... ул язган әсәрнең иң яхшысы вә иң тормыштан алынып язылгандыр дисәк җаиздер (дөрестер). Бу әсәрдәге бәян ителгән хәлләр, тасвирларның бер кыйсьме (өлеше) мөхәрриринең үз тормыш вә әхваленә гаид кебек (мөнәсәбәтле) күренсә дә, билгомум (гомумән) бөтенебез, чапкыр тормыш артыннан җитмәгән һәм ничектер куарга да керешә алмаган шәкертләрнең хәл-әхваленнән гыйбарәттер” [14, 106 б.]. Күренә ки, тәнкыйтьче үз рецензияләрендә төп каһарман Хәмит башыннан узган хәлләрне, кичерешләрне татар шәкертләренә характерлы дип карый, чынбарлыкка мөнәсәбәт бизмәненнән югары бәя бирә. Моннан тыш 1910 елларда әдәби хәрәкәтнең гомуми үсеш тенденцияләрен барлаган мәкаләләрдә, еллык хисапларда язучы иҗатына һәрдаим мөнәсәбәт белдерелеп бара.

1917 елгы Октябрь борылышыннан соң яңа социокультурологик шартларда М.Гафури иҗатын өйрәнү тарихында яңа чор башлана. Әдипнең рухи мирасы максатлы һәм эзлекле рәвештә өйрәнелә башлый. Дөрес, инде бу вакытта М.Гафуриның прозадагы эшчәнлеге икенче планга калдырылып, шагыйрьнең иҗтимагый-социаль лирикасы марксистик-ленинчыл эстетика, социализм идеологиясе кысаларында тикшерелә. 1920-1950 елларда Г.Ибраһимов, Г.Сәгъди, Г.Нигъмәти, М.Җәлил, Х.Госман, М.Гайнуллин, Ж.Вәзиева һ.б.ларның хезмәтләрендә шул чор әдәбият белеменең төп принципларыннан исәпләнгән сыйнфыйлык, партиялелек ноктасыннан әдипнең иҗат юлына, лирик герой кичерешләренә һәм бирелешенә күзәтү ясала, аерым әсәрләренә художество эшләнеше ягыннан да әтрафлы анализ

бирелә. Аларда шагыйрьнең “Кызыл байрак” (1917), “Эшче” (1921), “Кара йөзләр” (1927), “Тормыш баскычлары” (1928) һ.б. әсәрләре совет әдәбиятының төп методы буларак тәкъдим ителгән социалистик реализмның тәүге үрнәкләре итеп танылсалар да, М.Гафуриның сәнгатьчә фикерләү мәсьәләсе калкытып куелмый.

1960-1980 елларда М.Гафуриның тормыш юлын һәм рухи мирасын гыйльми-нәзари өйрәнү юлында җитди уңышларга ирешелә. Г.Халит, Н.Юзеев, М.Мәһдиев, Ә.Нигъмәтуллин, Г.Рамазановларның күләмле хезмәтләре дөнья күрә. Рус әдәбият белемендә әдәби юнәлешләр һәм иҗат методлары тирәсендә барган әдәби бәхәсләр, дискуссияләр татар әдәби җәмәгатьчелегендә дә зур кызыксынулар уята, шушы өлкәдә җитди тикшеренүләр башлана. М.Гафури шигърияте һәм прозасы да әдәби юнәлеш һәм иҗат методлары проблемасы яссылыгында гыйльми күзаллау предметына әверелә.

Билгеле булганча, М.Гафури – реалист язучы. Ул XIX гасыр мәгърифәтчелек әдәбияты традицияләрендә тәрбияләнеп, әдәби иҗатка килеп керә һәм аларны үзенең башлагыч чор әсәрләрендә үстереп алып китә. Дөнья әдәбияты тәҗрибәсе күрсәткәнчә, бер генә иҗат методы да саф килеш яши алмый. Татар әдипләре, шул исәптән М.Гафури тарафыннан үзләштерелгән мәгъифәтчелек реализмы да Рус-Аурупа әдәбиятларына хас сәнгатьчә фикерләү агымнарының йогынтысын тоя. М.Гафуриның XX гасыр башы әдәби эшчәнлегендә иҗат ысулын тикшерү шушы юнәлештә алып барыла.

Әдәбият галиме Г.Халит “Фәкыйрьлек белән үткән тереклек” (1902) хикәясенең реалистик әсәр булуын таныган хәлдә, аңа сентиментализмның йогынтысын билгели һәм ул реализмны катлауландырып, аның яңа төсмерен - сентименталистик реализмны тәкъдим итә: “Фәкыйрьлек белән үткән тереклек” хикәясе... үзенең стиле белән шул чордагы татар мәгърифәтчелек прозасына хас сентименталь реализмны һәм дидактизмны икенче чынбарлыкка – турыдан-туры халык чынбарлыгына бәйләнештә дәвам иттерүе әдип иҗатының буеннан-буена үткән зур теманы – халык язмышы

темасын, халык образын күтәрүе белән әһәмияткә ия” [15, 15 б.]. Ә чираттагы хезмәтендә галим, әсәрнең реалистик хикәя булуын тагын бер кат раслап, андагы натуралистик күренешләргә дә игътибар итә һәм сентиментальлекнең булуын дәлилләп чыга: “Ярлы кешеләр кичергән күңелсез хәлләрне куертуның аларны кызгандыру максаты белән эшләнүе дә, ягъни сентиментальлек тә сизелеп тора” [13, 273 б.]. Г.Сәгъди дә XX йөз башы татар әдәби хәрәкәтен яктырткан дәреслек-кулланмасында әдипнең башлангыч чор иҗатында сентиментализмның барлыгын һәм аның мәгърифәтчелек реализмы белән янәшә яшәвен күрсәтеп уза: “Әдәби агым ягыннан исә монда инде рационалистлык белән сентименталистлык бу шагыйрьдә бер тамырның ике тармагы, яисә бер үзәкнең ике кыягы булып үсә башлаган иде” [12, 207 б.].

Сентиментализм билгеләренең урын алуы татар әдәбияты өчен характерлы бер күренеш була, аның үсешендәге бер закончалыкны чагылдыра. Әлеге тенденция Г.Исхакый, С.Рәмиев, Г.Камал һ.б. әдипләр иҗатында да күренә. Г.Исхакый М.Гафуриның “Үги балалар” әсәре дөнья күргәч, хикәянең геройларына сентименталь мөнәсәбәтнең булмавын тәнкыйтьләп тә чыга: “Аларның үги аналарының вә тупас аталарының җәбере аркасында әллә ни кадәр җисми генә түгел, рухи да җәза кыйлынуларын укучының күзеннән яшьләр агызырлык иттереп тасвир итәргә тиеш иде” [5, 143 б.]. Аңлашыла булса кирәк, бу елларда формалаша башлаган әдәби тәнкыйть тә татар әдәбиятында сентиментальлекне яклап тавыш биргән, хәттә таләп итеп чыккан.

Әдипнең “Ярлылар яки Өйдәш хатын” повесте (1907) аның иҗатында реалистик башлангычны көчәйткән, тәнкыйди сыйфатларны ачыграк чагылдырган әсәр булып тора. Шуңа нигезләнеп, И.Нуруллин М.Гафури реализмының яңа баскычка – тәнкыйди реализмга күчүе турында нәтиҗә ясый: “М.Гафуриның шул ук 1907 нче елда язылган “Ярлылар яки Өйдәш хатын” повестен “Базарга чыктым” шигырендәге идеянең проза чаралары ярдәмендәге гәүдәләнеше итеп карарга мөмкин. Мәгърифәтчелек

реализмыннан килә торган кайбер кимчелекләренә карамастан, без аны тәнкыйди реализмның беренче карлыгачлары җөмләсенә керткән идек” [10, 231 б.]. Әсәрдә реалистик хикәяләүнең аныклыгы, язучының чынбарлык күренешләрен аңлавында тирәнлек, социаль каршылыкларга шактый урын бирелүгә карамастан, повесть мәгърифәтчелек реализмы кысаларында язылган, чөнки анда конфликт байлык, табышка омтылу, иҗтимагый мөнәсәбәтләр тирәсендә бармый, ә һөнәрсезлеккә, әхлаксызлыкка басым ясалып, каршылык мораль-әхлакый яссылыкта тудырылган. Шәриф, Бәдри, аеруча Җәмиләләрнең рухи сафлыгына, мәрхәмәтлелегенә байларның, күңел тупаслыгы, комсызлыгы, кешелексезлеге каршы куелган. Әсәрдә мораль-әхлакый югарылыкка, шәфкатьлелеккә, кешелеклелек сыйфатларына дан җырлана.

М.Гафури прозасының 1910 нчы елларда әдәби юнәлеш, иҗат методы ягыннан төрлеләнүе, катлаулануы әдип иҗатының милли әдәбияттагы алга таба үсеш-үзгәреш процессыннан аерылгысыз булуын раслый. Ул гына да түгел, язучы үз хикәя-повестьлары белән бу сыйфат яңарышына үзеннән өлеш тә кертә, баета, тулыландыра. Биредә сүз М.Гафури иҗатында көчәйгән романтик башлангыч, романтик тенденцияләр турында бара. Әдәби тәнкыйди фикер бу сыйфат үзгәрешенә дә сак якын килә. Аның иҗатында романтик үзенчәлекләрне танып та, язучыны реализм юлыннан читкә чыгармаска тырыша. “Ул да мәхәббәт, табигать культын һәм милли героиканы идеаллаштырган әсәрләр язды. Боларда күп кенә идея-эстетик каршылыклар булуга карамастан, Гафури иҗатына тамырларын тирән җибәргән реализмны романтизм кысрыклап басып китә алмады, ә киресенчә - реализмның лирик-психологик яңгырашын көчәйтүгә этәргеч бирде” [15, 18 б.]. Г.Халит авторның аерым әсәрләрендә реализм белән романтизмның синтезын билгеләп, реализмның “романтик реализм” дигән төсмерен аерып чыгара. Ә бит әдипнең реалистик әсәрләре белән беррәттән, романтик хикәяләре булуын, ягъни романтизмның барлыгын әдәбият галиме Г.Сәгъди 1920 нче елларда ук ассызыклаган иде: “Мәҗитнең шигыреннән башка тагы

аның романтизм юлында һәм реализм сызыгындарак язган күп кенә хикәяләре дә булды” [13, 214 б].

М.Гафури иҗатында тирән эз калдырган романтик иҗат алымнарының, романтик образларының чыганагы итеп ике башлангычны күрсәтергә кирәк:

1. Урта гасыр романтик иҗат традицияләре. Алар, үз нәүбәтендә, Шәрык әдәбиятыннан һәм халык авыз иҗатыннан киләләр.

2 Заман җиле (ХХ гасыр башы инкыйлабы) белән килүче хыял-омтылышларының романтик сурәт-образларга төрелеп бирелүе. Бу очракта Аурупа-рус әдәбиятларының тәэсире дә күздә тотыла.

Мәхәббәт тарихын шәркый традицияләрдә романтик күтәренкелек белән сурәтләгән “Заятүләк берлә Сусылу” (1909) дастаны, тарихи үткәнгә мөрәҗәгать итеп, легендаларны, халык иҗаты темаларын, образларын файдаланып язылган “Болгар кызы Айсылу” (1910) һәм эпистоляр жанрдагы “Мәхәббәт хатлары” (1912) хикәяләрендә романтизмның чагылышын күрәбез.

1990 елларда моңа кадәр Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Ибраһимовлар һ.б. лар белән янәшә куелып, дәвамлы өйрәнелеп киленгән М.Гафуриның иҗат биографиясен яктыртуда замана җилләре тәэсирендә өзеклек барлыкка килә. Шушы елларда кире кагу рухы белән мавыгып китеп, аның аерым әсәрләре турында дөреслектән ерак торган берьяклырак фикерләр дә яңгырый. Әмма гыйльми-тәнкыйди фикер тиз арада бу шаукымнан арынып, М.Гафуриның иҗатын барлап, яңача шәрехләүгә, заман сынавын узмаган бәя-хөкемнәрне төзәтүгә алынды. Әдипнең тууына 120 ел, 125 ел тулу уңаеннан Татарстан һәм Башкортстан республикаларында үткәрелгән фәнни-гамәли конференция материалларында, З.Рәмиев, Т.Галиуллин, Х.Миңнегулов, Д.Заһидуллина һ.б. ларның хезмәтләрендә әдип иҗатының идея-эстетик үзенчәлекләре, милли әдәбияты үстерүгә һәм баетуга керткән казанышларына, шул уңайдан язучының сәнгатьчә фикерләү ысулына да игътибар юнәлтелә.

Мәҗит Гафури рухи мирасын яңадан кайтып өйрәнү, гомумкешелек кыйммәтләр, миллилек-татарлык принцибы яктылыгында гыйльми күзаллау,

иҗат ысуллары-методлары проблемасын тикшерү әдип мирасының олылыгын, без уйлаганнан шактый катлаулы, бай һәм бүгенге милли яшәешебез өчен әһәмиятле булуын күрсәтә. М.Гафури иҗаты, һичшиксез, XX йөз башы һәм 1920 еллар татар әдәбияты белән тыгыз бәйләнештә үрелеп үсә, милли сүз сәнгатенең яңа биеклекләргә күтәрелүенә үзеннән лаеклы өлеш кертә. Әдәби юнәлеш, иҗат методлары ягыннан аның әдәби мирасы катлаулы иҗат мәйданы булып тора. XX гасыр гыйльми-тәнкыйди фикере аның рухи мирасында реализмның төрле төсмерләрен, сәнгатьчә фикерләүнең романтик төрен, сентиментализм һәм модернизм әдәбиятлары үзенчәлекләрен, натуралистик тенденцияләрне аерып чыгара.

**Искәрмәләр.**


1. Әмирхан Ф. Әсәрләр 4 томда. 4-т. / Әдәбият - сәнгать тәнкыйте, биографик материаллар, хатлар. - Казан: Татар.кит.нәшр., 1986. - 389 б.

2. Галиуллин Т. Шигърият баскычлары: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. – Казан: Мәгариф, 2002. – 231 б.

3. Заһидуллина Д. Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 255 б.

4. Ибраһимов Г. Әсәрләр сигез томда. 5-т. 1 Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910-1933). - Казан: Татар.кит.нәшр., 1978. - 614 б.

5. Исхакый Г. «Үги балалар» // Әсәрләр. Унбиш томда. 6-т.: Публицистика һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 141-145 б.

6. Камал Г. Әсәрләр өч томда. 3-т. / Хикәяләр, мәкаләләр, рецензияләр, истәлекләр (1900-1933). - Казан: Татар.кит.нәшр., 1981. - 4146.

7. Мәһдиев М. Мәҗит Гафури // Әдәбият һәм чынбарлык: XX йөз башы татар әдәбияты тарихына яңа материаллар. - Казан, 1987. - 3-29 б.

8. Миңнегулов Х. Татарның бөек бер моңчысы // Казан утлары. – 2010. - № 8. – 137-146 б.

9. Нигъмәтуллин Ә. Мәҗит Гафури (Иҗаты турында очерк). - Казан: Татар.кит.нәшр., 1969. - 93 б.

10. Нуруллин И. XX йөз башы татар әдәбияты. – Казан: Татар.кит.нәшр.; 1982. – 285 б.

11. Рамазанов Г, Юзиев Н. Мәҗит Гафури // Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. - 4-т. / Татар совет әдәбияты (1917-1941). - Казан, 1989. – 50-67 б.

12. Рәмиев З. Тукай һәм замандаш әдипләр: “Габдулла Тукай” энциклопедик сүзлек белешмәсенә материаллар. – Казан: ТаРИХ, 2004. – 111 б.

13. Сәгъди Г. Татар әдәбияты тарихы: Дәреслек -кулланма. - Казан: Татгосиздат. - 1926. - 300 б.

14. Тукай Г. Әсәрләр. Дүрт томда. 4-т. / Мәкаләләр. Очерклар. Фельетоннар. Хатлар. (1902-1913). - Казан: Татар.кит.нәшр., 1977. – 431 б.

15. Халит Г. Тормыш һәм ирек җырчысы: Мәҗит Гафуриның тормышы һәм иҗаты турында очерк. - Казан: Татар.кит.нәшр., 1980. - 183 б.

16. Халит Г. Проза // Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. 3-т. / XX гасыр башы. - Казан: Татар китап нәшр., 1986. - 598 б.